Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советының илле дүртенче утырышы

Кибәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2019 елның 23 сентябре, № 135

Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча
дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында

Россия Федерациясенең нотариат турында 1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы закон Нигезләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1, 20 статьялары нигезендә Кибәч авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты секретарен яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә:

1) күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен раслауга;

2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрүгә;

3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең чынлыгын раслауга;

4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләүгә;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклауга;

6) гражданның исән булу фактын таныклауга;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз кулы белән имзасының, үз кулы белән имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген раслауга;

8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклоуга;

9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклауга;

10) документлар тапшыру вакытын таныклауга;

11) документның кәгазьдә урнаштырылган документның бердәйлеген раслауга;

12) документның кәгазьдә электрон документка тиңлелеген таныклауга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советының 2011 елның 11 гыйнварында кабул ителгән 1 номерлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru,

Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) әлеге карарны игълан итәргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.А.Рәимов